КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 апрель г.Казань № 318

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 11 июнь, 431 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү күләмен билгеләү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 11 июнь, 431 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 28 август, 755 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү күләмен билгеләү тәртибенә, преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 213 статьясындагы беренче өлеше,

«Хезмәт шартларын махсус бәяләү турында» 2013 елның 28 декабрендәге 426-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы өченче өлеше, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздыру тәртибен раслау турында» 2021 елның 29 октябрендәге 775н номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин